РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕНЫРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул.Школьная, 10, село Большие Нырси, 422094,
Тел.: (884360)53-1-25(факс)
E-mail: Bnrs.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРСЫ АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп урамы, 10 Олы Нырсы авылы, 422094
Тел.: (884360)53-1-25(факс)
E-mail: Bnrs.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318116 ОГРН 1061675010847 ИНН/КПП 1619004450/161901001


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№13**

**КАРАР**
**«13» август 2020 г.**

Теләче муниципаль районының Олы Нырсы авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Олы Нырсы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында

«2020 елның 13 сентябрендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» Татарстан Республикасы Теләче районының 2020 елның 28 июлендәге 14/22 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теләче муниципаль районының Олы Нырсы авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Олы Нырсы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- 10 йорт, Мэктэп ур., Олы Нырсы авыл җирлеге бинасында мәгълүмат стенды;
- 29 йорт, Ленин ур. Олы Нырсы кибет янында мәгълүмат стенды;
- 12 йорт, Спутник ур., Кече Мирэтэк авылы, авыл клубы янында мәгълүмат стенды;
- 9 йорт, Пушкин урамы, Иске Карабаян авылы, торак йорт фасадында мәгълүмат стенды;

- Карл Маркс урамы, Кече Нырсы авылы, тукталыш павильонында мәгълүмат стенды;

- Ленин урамы, Тәмте авылы, тукталыш павильонында мәгълүмат стенды;

- 12 йорт, Совет урамы, Карабаян авылы, торак йорт фасадында мәгълүмат стенды

2. Олы Нырсы авыл җирлеге башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында» 2019 елның 25 июль №25 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Олы Нырсы авыл җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча: 10 йорт, Мәктәп ур., Олы Нырсы авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Теләче муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Р.М.Гиниятов